МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.02.2024 Казан ш № 110

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 12.07.2018 №550, 10.09.2018 №842, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1040, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403, 19.10.2021 №770, 16.06.2022 №554, 29.08.2022 №813, 14.11.2022 №1000, 20.06.2023 №475 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

ОТДЕЛ ДЕЛО-ПРОИЗВОДСТВА

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
16.02.2024 ел, №110
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1 пунктны «(алга таба – Административ регламент)» сүзләре белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент Россия Федерациясе Президентының «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итү буенча дәүләт фонды төзү турында» 2023 елның 3 апрелендәге Указының 2 пунктындагы «в» пунктының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән гражданнарга да кагыла.»;

әлеге боерык белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.3 пунктын өстәргә:

«2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы карарны үз эченә алган документлар реквизитлары:

хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле органның атамасы;

хезмәт күрсәтү өчен вәкаләтле органның урнашу урыны адресы;

хезмәт күрсәтергә вәкаләтле органның телефон номеры;

хезмәт күрсәтү өчен вәкаләтле органның электрон почта адресы;

документның исеме;

карар кабул итү номеры һәм датасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәре вазыйфасы;

хезмәт күрсәтү турында карар кабул иткән органның вәкаләтле хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);
электрон имза турында белешмәләр.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.4 пунктын өстәргә:

«2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.»;

2.6.6 пунктның тугызынчы абзацында «(Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы»))» сүзләре белән алмаштырырга;

2.6.7 пунктында «2.5 пунктында» сүзләрен «2.6.1 пунктында» сүзләре белән алмаштырырга;

2.7.1 пунктның икенче абзацында «2.5 пунктында» сүзләрен «2.6.1 пунктында» сүзләре белән алмаштырырга;

3 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле $3.1^1$ - $3.1^2$ пунктларын өстәргә:

«$3.1^1$. Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар белән һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында шартнамәләр төзүне оештыру.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында шартнамәләр төзи.

Үтәү вакыты: процедура «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль законда күрсәтелгән срокларга ярашлы рәвештә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзелгән шартнамәләр.

$3.1^2$. «Россиядә эш» порталында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның реестрын формалаштыру һәм алып бару.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар белән төзелгән шартнамәләр турында мәгълүматны «Россиядә эш» порталына кертә.

Үтәү вакыты: процедура шартнамә төзелгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның формалаштырылган реестры.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.2^1$-$3.2^3$ пунктларын өстәргә:

«$3.2^1$. Мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

$3.2^2$. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гариза бирүче турында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган органнар, муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар, бюджетка карамаган дәүләт фондлары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына карый торган оешмалар карамагында булган түбәндәге белешмәләрне сората:

паспортның гамәлдә булуы турында белешмәләр – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

яшәү (тору) урыны буенча теркәү турында белешмәләр – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан;

хезмәт эшчәнлеге турында, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан;

хезмәт стажы турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

соңгы эш (хезмәт) урыны буенча мәҗбүри пенсия иминиятенә иминият кертемнәре күчерелгән түләүләр һәм башка бүләкләр турында мәгълүматдар – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан;

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

белеме, квалификациясе турында белешмәләр – Рособрнадзор («Белем турында һәм (яки) квалификация, белем алу турында документлар турында мәгълүматларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

пенсия алды яшендәге гражданнарга кертелү турында мәгълүматлар – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондыннан («Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы).

Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура гариза бирүчене теркәү исәбенә куйганнан соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: ведомстволарга җибәрелгән сораулар.

3.2$^{3}$. Әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш итеЛә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара гариза алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатькә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралган белешмәләрнең булмавы турында халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрелгән хәбәр.».

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар һәм ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алынган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында яисә әлеге Регламентның 2.8.2 пунктында күрсәтелгән нигезләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгече гариза бирүчегә «Россиядә эш» порталын кулланып хәбәр җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белгече «Россиядә эш» порталын кулланып, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим төзи һәм җибәрә.

Процедураларны үтәү вакыты: процедура халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә гариза кергән көнне яки, гариза халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең эш вакытыннан соң алынган очракта, икенче көнне гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында җибәрелгән тәкъдим.»;

түбәндәге эчтәлектәге $3.30^1$-$3.30^3$ пунктларын өстәргә:

«$3.30^1$. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җирләргә җибәрелгән гариза бирүчегә финанс ярдәме күрсәтү турында карар кабул итә.

Гариза бирүче үзе халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмадан чыгарылганнан соң бер айдан да соңга калмыйча башка җирдә һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу чыгымнарын раслаучы документларны тапшыра.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге карары гариза бирүчегә финанс ярдәме күрсәтү турында (тәкъдим ителгән үрнәк Стандартка 4 нче кушымтада китерелгән) (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) яки гариза бирүчегә финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында (тәкъдим ителгән үрнәк Стандартка 5 нче кушымтада китерелгән) (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта) боерык рәвешендә рәсмиләштерелә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге «Россиядә эш» порталын кулланып, гариза бирүчегә финанс ярдәме күрсәтү турында хәбәр җибәрә.

Процедураларны үтәү вакыты: процедура боерык чыкканнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә финанс ярдәме күрсәтү турында җибәрелгән хәбәр.

3.30[2]. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, гариза бирүчене белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмадан чыгару турында мәгълүмат алганнан соң, «Россиядә эш» порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә төзи, ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

гариза бирүче сайлаган һәм алар буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алуны гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында тамгалап, киңәш ителә торган һөнәрләрнең (белгечлекләрнең) исемлеге;

укыту өчен тәкъдим ителгән укыту программалары исемлеге;

укыту процессын оештыру турында белешмәләр (һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау һәм халыкны эш белән тәэмин итү зәге белән гариза бирүче арасында белем алуга юллама алу турында шартнамә реквизитлары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың исеме; курс программасының исеме; укуның башлану һәм тәмамлану даталары);

гариза бирүчене һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җирлеккә юллаганда финанс ярдәме күрсәтелүе турында белешмәләр.

Процедураларны үтәү вакыты: процедура гариза бирүченең белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмадан чыгарылуы турында мәгълүмат алганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: «Россиядә эш» порталын кулланып төзелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә.

3.30[3]. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, «Россиядә эш» порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне гариза бирүчегә җибәрә.

Процедураларны үтәү вакыты: процедура бәяләмә төзелгән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында җибәрелгән бәяләмә.»;

түбәндәге эчтәлектәге 5 нче һәм 6 нчы кушымталар белән тулыландырырга:

«Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Үрнәк

ПРИКАЗ

«__» _________ 20__ ел. №_____

Халыкны эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җирләргә җибәрелгән гражданинга финанс ярдәме күрсәтү турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 23 статьясына таянып:

Финанс ярдәме күрсәтергә ______________________________________________

(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

(дәүләт хезмәтләрен алучының шәхси эше__________ 20__ №_________ )
_____ сум _______ тиен күләмендә, шул исәптән:

1. Уку урынына һәм кирегә кайту өчен түләү _____ сум _____ тиен.
2. Уку урынына бару һәм кире кайту өчен тәүлеклек чыгымнар _____ сум _____ тиен.
3. Уку чорында торак бинаны арендага алу өчен түләү 20 ___ елның «__» ______ башлап 20___ елның «__» _______ кадәр ____ сум ____ тиен күләмендә.

Татарстан Республикасы
халыкны эш белән
тәэмин итү хезмәте
дәүләт учреждениесе
хезмәткәре

| ________________ | ____________ | ___________________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)) |

Татарстан Республикасы
халыкны эш белән тәэмин итү
хезмәте дәүләт учреждениесе
җитәкчесе

| ______________________ | ______________________________ |
|---|---|
| (имза) | (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)) |

Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча

дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Үрнәк

ПРИКАЗ

«__» __________ 20__ ел. №_____

Халыкны эш белән тәэмин итү органнары тарафыннан һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җирләргә җибәрелгән гражданинга финанс ярдәме күрсәтүдән баш тарту турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 23 статьясына таянып:

Финанс ярдәме күрсәтүдән баш тартырга ______________________________________

(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

(дәүләт хезмәтләрен алучының шәхси эше__________ 20__ №_________ )

түбәндәге-ләргә бәйле рәвештә: ________________________________________________

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе хезмәткәре ______________ ____________ ______________________________

(вазыйфа) (имза) (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе җитәкчесе ____________________ ______________________________

(имза) (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта))».